Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

28 август 2020 ел №389

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр түбәндәге очракларда бирелә:

башка дәрәҗәдәге хакимият органнары карарлар кабул иткән очракта чыгымнарны компенсацияләүгә акча бирү;

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл иткәндә барлыкка килә торган вакытлы касса өзеклекләрен каплауга акчалар бирү;

гамәлдәге законнар нигезендә өстәмә чыгымнар барлыкка килгән очракларда.

2. Субсидияләр чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджеты турында Әлмәт муниципаль районы Советы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләренең төп бүлүчесе - Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (алга таба - Финанс-бюджет палатасы).

4. Әлмәт муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бүлү Әлмәт муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты турындагы карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирү максатлары һәм шартлары әлеге карар нигезендә Финанс-бюджет палатасы приказы белән расланган типлаштырылган форма нигезендә җирлекнең Финанс-бюджет палатасы башлыгы һәм җирле администрация башлыгы (вәкаләтле орган җитәкчесе) арасында төзелә торган килешү белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидиянең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм тоту шартлары;

в) субсидияләр бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидияне күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе;

е) финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү Финанс-бюджет палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8.Килешү проекты җирлеккә финанс-бюджет палатасы тарафыннан җибәрелә.

9. Килешүгә Финанс-бюджет палатасы рәисе һәм җирлекнең җирле администрациясе башлыгы (вәкаләтле орган җитәкчесе) имза сала.

10. Җирлек субсидияне килешү белән билгеләнгән срокларда алу өчен Финанс-бюджет палатасына килешүдә билгеләнгән форма буенча субсидияләр бирүгә гариза бирә.

11. Җирлекләр бюджетларына бирелә торган субсидияләр күләме Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты билгеләгән формула (исәпләүләр) буенча билгеләнә.

12. Субсидияләр Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары счетларына җирлекләр бюджетларына финанс-бюджет палатасы тарафыннан килешүдә билгеләнә торган срокларда җирле бюджетларны үтәүгә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган счетларга күчерелә.

13. Субсидияләр бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән тәртиптә Әлмәт муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

14. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 январенә файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлеше Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Әлмәт муниципаль районы бюджеты керемenә кайтарылырга тиеш.

15. Бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшереп торуны Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Финанс-бюджет палатасы законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

16. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

17. Әлеге карарның нигезләмәләре, 2020 елгы бюджетлардан башлап, бюджетларны төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

18. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Муниципаль район Башлыгы — Т.Д. Нагуманов